ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕОШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.37 А, с. Нижняя Ошма,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422164

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТҮБӘН УШМЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Советлар ур., 37 А нче йорт,Түбән Ушмы авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422164

тел.(факс): (85563) 2-34-46; e-mail: Noshm.Mam@tatar.ru, www:mamadush.tatarstan.ru

---

Постановление — Карар

№ 20 — от 11.11.2022 ел.

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы « Түбән Ушмы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст. нигезендә, «Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы» җыеннар карарларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге башкарма комитеты;

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлегенең Хафизовка торак пунктында 2023 елда үзара салым кертү турында»2022 елның 28 октябрендәге 1 номерлы;

« Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге составына керүче Хафизовка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 28 октябрендәге 2 номерлы карары,

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлегенең Түбән Ушмы торак пунктында 2023 елда үзара салым кертү турында»2022 елның 28 октябрендәге 3 номерлы;

« Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге составына керүче Түбән Ушмы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 28 октябрендәге 4 номерлы карары,

к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Ушмы  авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасы җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы  авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://mamadysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru). бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз контролемә алам.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Ушмы  авыл җирлеге
башкарма комитеты рәисе /Р.М.Ганиев/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Ушмы авыл җирлеге
Башкарма комитетының 11
ноябрь 2022 ел, 20 санлы
карарына 1 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Ушмы авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Түбән Ушмы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар 2023 елның 26 мартына кадәр үзара салым акчаларын җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, түли.

3. Җитди сәбәпләр булганда:

а) вакытлыча эшкә сәләтсезлек,

б) хезмәт командировкасы,

гражданнарга гариза нигезендә, бер айдан да артмаган вакытка түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга аны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, җиткерелә, шулай ук шәхсән кул куйдыртып яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җибәрелә ала.

Хәбәрнамәдә (хәбәрнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

7. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия

булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Ушмы авыл җирлеге
Башкарма комитетының 11
ноябрь 2022 ел, 20 санлы
карарына 2 нче кушымта

___________________________
(*муниципаль берәмлек исеме)*

бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _______________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________

Адрес: ____________________________________________________________

Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлегенең ___________ авылында гражданнар җыены карары нигезендә 2023 нче елда үзара салым акчаларын куллану һәм кертү мәсьәләсе буенча Сезгә 2023 елда халык җыены чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр ______ сум күләмендә түләүне, түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк: __________________________________________________

Кабул итүче як банкы БИК ______________________________________
Сч. № ___________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № _______________________________________
ИНН _____________________________________
КПП _____________________________________
КБК _______________ ОКАТО ___________________
Түләүнең билгеләнеше
Гражданнарның үзара салым түләве

Җитәкче __________________ ________________________________________
П. У. (имза) (тулысынча язылыш)

**- - - - - - - - - - - - - - - - кисеп алу сызыгы - - - - - - - - - - - - - -**

________________________________________________________
(*муниципаль берәмлек исеме)*

________________ сум күләмендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _________________

Түләүченең Ф.И.Ә.и.
________________________________________________________

Адрес:

__________________________________________________________________________________

«__» ________________ 20__ г. ____________________________________________

(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегү шәхсән тапшырылган очракта, өземтә (корешок)_______________ авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.*